

14 март конне Рузаевка районынын Шәриф Камал исемендәге Татар Пешлә урта мәктәбендә “Без жинәчәкбез!” (“Мы победим!”) дигән чара Боек Ватан сугышында Жинvнен 80 еллыгына һәм татар әдәбияты классигы Шәриф Камал ижатына багышланган иде.
Конференциянен тантаналы олешендә мәртәбәле кунаклар: Татар Пишләсе авыл жирлеге администрациясе башлыгы Ринат Дәvлvк улы Шабаев, Рузаевка “ИМЦ” директоры Наталья Викторовна Щербакова, Саранскта урнашкан “Рухи-мәдәни vзәк” директоры урынбасары Надия Низаметдин кызы Азисова катнаштылар. Сәламләv сvзе белән Шәриф Камал исемендәге Татар Пешлә урта гомуми белем бирv мәктәбе директоры Флора Ахмәтжан кызы Шамонова чыгыш ясаган.
Официаль рәсми ачылыштан сон катнашучылар секцияләргә таралып жанлы дискуссияләр, мастер-класслар һәм ижади чыгышлар булган. Педагогическая” секциясендә Рузаевка районы педагоглары кыйммәтле тәжрибәләре белән уртаклашканнар. Укучылар татар һәм мордва шагыйрьләренен сугыш елларындагы батырлыгы һәм каһарманлыгы белән сугарылган шигырьләрен “Без сугыш турында шигырьләр сойлибез” номина-циясендә яттан сәнгатьле иттереп сойләгәннәр. “Когда строка диктует чувство” секциясендә Шәриф Камалнын рус һәм татар телләрендәге әсәрләреннән озек-ләр янгыраган, ижатынын ма-турлыгын һәм тирәнлеген югары дәрәжәдә Саитов Альмир (8 кл.), Гундина Камила (кл.), Сафарова Зухра (11кл.) кvрсәткәннәр. Торле конкурсларда ин осталары: “Без сугыш турында шигырьләр сойлибез” номинациясендә Дубинникова Диляра (7 кл.), Щетинин Иван (5 кл.); “И строчка каждая рисунком хочет стать” - Тужилкина Арина (8кл.); “Балалар кvзе белән сугыш” - Лилия Крюкова (5 кл.) һәм башкалар.
Конференция белем, тәжрибә һәм ижади идеяләр белән уртаклашу мәйданчыгына әверелгән; районнын мәдәни тормышында якты эз калдырган. Әлеге чарада катнашкан Наилә Идрис кызы Башмакова конференция турында болай ди: “Без жинәчәкбез!” конференциясен профессиональ оештырган очен ихлас рәхмәтемне белдерәсем килә. Эчтәлекле чара югары дәрәжәдә узды һәм файдалы булды. Атмосфера гажәеп ягымлы, якты, онытылмаслык якты тәэсирләр белән тулы иде. Мин әлеге конференцияне әзерләvгә кvпме коч салынганын анлыйм һәм сезнен хезмәтегез һәм осталыгыгыз очен зур рәхмәт әйтәсем килә. Кунакчыллык һәм жылы кабул итv очен аерым рәхмәт”.